КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 30 гыйнвар г.Казань № 49

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт органы һәм Россия Федерациясе гражданы арасында белем алып бетергәннән соң алга таба билгеле бер вакыт эчендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үтү йөкләмәсе белән белем алуга шартнамә төзү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 8 август, 640 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 17 октябрь, 932 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт органы һәм Россия Федерациясе гражданы арасында белем алып бетергәннән соң алга таба билгеле бер вакыт эчендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үтү йөкләмәсе белән белем алуга шартнамә төзү тәртибе турындагы нигезләмәгә, 7 пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«г) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында кәгазьдә расланган белешмә яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә;".

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Рус теле һәм әдәбияты өлкәсендә югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча фәнни-педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү буенча грантлар бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 ел, 20 сентябрь, 661нче карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 12 декабрь,  78 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Рус теле һәм әдәбияты өлкәсендә югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча фәнни-педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы галимнәргә

һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү буенча грантлар бирү турындагы нигезләмәгә, 11 пунктның «б» пунктчасын «һәм (яки) тиешенчә танылканган кәгазьдә хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләрне, көчәйтелгән квалифицияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә» сүзләре белән тулыландырып, үзгәреш кертергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгариф өлкәсендә грантлар турында» 2009 ел, 8 август, 648 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 31 октябрь, 975 нче, 2009 ел, 31 октябрь, 990 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Татар теле һәм әдәбияты укытучыларына татар теле һәм әдәбияты буенча республика олимпиадаларында, татар теле һәм әдәбияты буенча Халыкара олимпиадада җиңүчеләрне һәм призерларны әзерләгән өчен ярдәм» гранты турында нигезләмәнең 10 пунктындагы дүртенче абзацына «, һәм (яисә) тиешенчә расланган кәгазьдә хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат, яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә" сүзләрен өстәргә»;

әлеге карар белән расланган «Безнең иң яхшы методист" гранты турындагы нигезләмәнең 10 пунктындагы алтынчы абзацына «, һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында кәгазьдә, тиешле рәвештә расланган яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында" сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен гомуми белем бирү оешмасының иң яхшы укытучысы» гранты турындагы нигезләмәнең 10 пунктындагы бишенче абзацында «, һәм (яисә) тиешенчә танылканган кәгазьдә хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләрне яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган «Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабы призерларын һәм җиңүчеләрен әзерләгән педагогик хезмәткәрләргә ярдәм» гранты турындагы нигезләмәнең 11 пунктындагы дүртенче абзацында «, һәм (яисә) тиешенчә расланган кәгазьдә хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар, яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин